Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина

ГОМУМИ УРТА БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА
ТАТАР ТЕЛЕН ТУГАН ТЕЛ БУЛАРАК ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕН
КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ
(яки татар әдәбиятын укытуның кыскартылган варианты)

5 нче сыйныф
Аңлатма язуы

Татар әдәбияты дәресләренең төп бурычлары:

• татар әдәбияты тарихының төп фактларына нигезләнеп, әдәби әсәрне уку һәм анализлау күнекмәләре формалаштыру;

• матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку ихтыяҗы булдыру;

• укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерү;

• татар халкына, аның әдәбияты һәм мәдәниятенә хөрмәт, дөньяга гуманлы караш, башка халыкларның мәдәниятләре белән кызыксыну тәрбияләү.

*5 нче сыйныфта татар әдәбияты фәне кимендә атнага 2 сәгатьтән ел буена 68 сәгать укытылырга тиеш. Нәкъ шул очракта гына әдәбият предметы буенча куелган максатларга өлешчә булса да ирешергә мөмкин. Әдәбиятны 68 сәгать күләмендә өйрәтү методикасы тулы күләмдә алда исемнәре күрсәтелгән әсбапларда, бәйнә-бәйнә, тәфсилләп, һәр дәресләп, дәрестә этаплап, минутлап һәм тасвирлап аңлатылды. Методик әсбапларны Казан шәһәрендә, Ямашев проспектындагы 51-71 нче офистан теләсә кайсы көндә сатып алырга була. “Мәгариф-Вакыт” нәшриятының үз сайты бар, телефоннары эшләп тора. (http://magarif-vakyt.ru E-mail: valeevmx@mail.ru) Соңгы вакытларда мәктәпләрнең күпчелегендә татар әдәбияты атнага берәр сәгатьтән, елга 34 сәгать күләмендә планлаштырыла. Предмет буенча әлеге тематик план шул очракны гына искә алып төзелде. Әдәби материалның яртысын, эчтәлеккә зыян китермичә, тулысынча кыскарту әдәбиятны укыту кануннарына берничек тә туры килә алмый. Кайбер дәресләрдә укытучының әдәби материалны төркемләп тә бүлеп бирүе күз алдында тотылды.*

Гомуми урта белем бирү оешмалары өчен Татар әдәбиятыннан программа Россия Федерациясенең “Мәгариф турында”гы Законы (7 нче маддә), Россия Федерациясе хөкүмәте раслаган (2001 нче ел, 29 нчы декабрь, №1756) “Россия мәгарифен яңарту Концепциясе”, Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы, “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (9 нчы маддә) кебек норматив документларга һәм татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандартларына нигезләнеп эшләнде.

**Эш программасын төзү өчен материал исемлеге:**

1. **Дәреслек:**
   Хәсәнова, Ф.Ф. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 5 нче с-ф. Ике кисәктә / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина; [рәссамы Фәридә Ризаева]. – Казан: “Мәгариф–Вакыт” нәшр., 2014. – 143 б, 119 б.

2. **Электрон дәреслек:**
   Хәсәнова, Ф.Ф. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 5 нче с-ф. Ике кисәктә / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина; [рәссамы Фәридә Ризаева]. – Казан: “Мәгариф–Вакыт” нәшр., 2015.

3. **Методик ярдәмлек:**
   Хәсәнова, Ф.Ф. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән) эшләүче укытучылар өчен методик әсбап. 5 нче с-ф. / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: “Мәгариф–Вакыт” нәшр., 2014. – 179 б.

4. **Эш дәфтәре (һәр укучы өчен контроль-диагностика материаллары)**
   Хәсәнова Ф.Ф. Һәр дәрескә тестлар: диагностика буенча эш дәфтәре. 5 нче сыйныф / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: “Мәгариф–Вакыт” нәшр., 2016. – 95 б.

5. **Сочинение язарга өйрәтү ярдәмлеге**
   Хәсәнова Ф.Ф. Сочинение язарга өйрәтәбез: укытучылар өчен методик кулланма / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: “Мәгариф–Вакыт” нәшр., 2016. – 159 б.

6. **Авторлык программасы**

Хәсәнова, Ф.Ф. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен татар әдәбиятыннан авторлык программасы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 5–9 сыйныфлар. Яңартылган, тулыландырылган, төзәтелгән 2 нче басма / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: “Мәгариф–Вакыт” нәшр., 2016. – 63 б.

## КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

| № п/п | Дәрес темасы, эчтәлеге, төп эшчәнлек төрләре | Дәрескә бирелгән сәгать саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт |
| 1. | БСҮ. Китап дигән могҗиза. Укучыга, И.Газиның “Үзе бер могҗиза”, дәреслек белән танышабыз, китап турында мәкальләр, кызыклы мәгълүматлар. (7-11 нче бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| | Татар халык авыз иҗаты (6 сәг.) | | | |
| 2. | 1. Фольклорның кече жанрлары. Татар халык авыз иҗаты турында, татар халык әкиятләре, әкиятләр белән танышабыз, халык әкиятләре төрләре (12-16 нче бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| 3. | 2. Татар халык әкиятләренең төзелеше. Әкиятләрнең төзелеше. (17-18 нче бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| 4. | 3. Тылсымлы әкият һәм аның геройлары (29-31 нче бит, 1 нче кисәк). Әкият герое буларак – атлар. | **1** | | |
| 5. | 4. “Үги кыз” әкияте (31–38 нче бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| 6. | 5. “Хәйләкәр төлке”, “Солдат балтасы” әкияте (39–42 нче бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| 7. | 6. БСҮ. Бишек җырлары. (6–8 нче бит – 2 нче кисәк). Тест тикшерүе. | **1** | | |
| | Халык авыз иҗаты белән рухланып... Мәсәлләр (1 сәг.) | | | |
| 8. | 1. Габдулла Тукай һәм Әхмәт Исхакның бер үк исемдәге мәсәлләре (43–46 нчы бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| | Хәзинә. Борынгы әдәбият үрнәкләре (2 сәг.) | | | |
| 9. | 1. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәре турында. Дастан, поэма жанрлары турында төшенчә. (49-52 нче бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| 10. | 2. Кол Гали. “Кыйссаи Йосыф”тан өзекләр уку. Артист укуында тыңлау. Электрон дәреслек буенча эшләү. | 1 | | |
| | XIX гасыр әдәбияты үрнәкләре (1 сәг.) | | | |
| 11. | 1. *Каюм Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты. “Патша белән карт”* һ.б. хикәятләрен уку (57-60 нчы бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| | XX гасыр башы әдәбияты үрнәкләре (сугышкача әдәбиятны да кертеп, 5 сәг.) | | | |
| 12. | 1. *Габдулла Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты. “Су анасы”* әкият-поэмасын уку (60-66 нчы бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| 13. | 2. *Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты. “Яз башы”* хикәясе (67-72 нче бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| 14. | 3. Галимҗан Ибраһимов. “Фагыйлә” хикәясе. Хикәя жанры (49-51 нче бит, 2 нче кисәк). | 1 | | |
| 15. | 4. *Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм башлангыч чоры иҗаты. “Алтынчәч”* либреттосыннан өзекләр уку (72-75 нчы бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| 16. | 5. Муса Җәлил. “Кызыл ромашка” шигырен уку. Баллада жанры (76-77 нче бит. 1 нче кисәк). I яртыеллыкка контроль эш. | **1** | | |
| | Сугыш чоры әдәбияты (5 сәг.) | | | |
| 17. | 1. Муса Җәлил. “Җырларым”, “Бүреләр” шигырьләрен укып анализлау (64-65 нче бит, 2 нче кисәк, 78-79 нчы бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| 18. | 2. БСҮ. Харис Якупов. “Хөкем алдыннан” картинасы буенча сорауларга җавап бирү, 79 нчы бит, 1 нче кисәк (телдән яки язма рәвештә – укытучы сайлый). | **1** | | |
| 19. | 3. Фатих Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты. “Кыр казы”*, “Ватаным өчен” шигырьләрен уку (81-84 нче бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| 20. | 4. Сибгат Хәким. “Колын” шигырен укып анализлау (88-89 нчы бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 21. | 5. | Яттан өйрәнгән шигырьләрне сөйләү. Тест тикшерүе | **1** | | |
| | | Сугыштан соңгы чор әдәбияты (4 сәг.) | | | |
| 22. | 1. | Фатих Хөснинең тормыш юлы һәм иҗаты. “Чыбыркы” хикәясе* (90-95 нче бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| 23. | 2. | Нәби Дәүлинең тормыш юлы һәм иҗаты. “Бәхет кайда була?”* шигырен укып анализлау (96-97 нче бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| 24. | 3. | Фәнис Яруллинның тормыш юлы һәм иҗаты. “Зәңгәр күлдә ай коена”* хикәясен укып анализлау (98-103 нче бит, 1 нче кисәк). | **1** | | |
| 25. | 4. | БСҮ. Бәхет турында сөйләшү. Теманы йомгаклау. Тест тикшерүе. | **1** | | |
| | | Туган ил, туган як турында (5 сәг.) | | | |
| 26. | 1. | Нәкый Исәнбәт. “Туган ил” шигырен уку, ятлау, анализлау (104-105 нче бит, 1 нче кисәк). | 1 | | |
| 27. | 2. | БСҮ. Туган як табигате. Дәреслектә бирелгән картиналар буенча сөйләшү (106-107 нче бит, 1 нче кисәк). | 1 | | |
| 28. | 3. | Фоат Садриевнең “Тургай ни дип җырлый?” хикәясен укып анализлау (110-112 нче бит, 1 нче кисәк). | 1 | | |
| 29. | 4. | Гамил Афзал, Разил Вәлиев шигырьләрен укып анализлау (92-93 нче бит, 2 нче кисәк). | 1 | | |
| 30. | 5. | Мөдәррис Әгъләмовның “Матурлык минем белән”* шигырен укып анализлау (115-116 нчы бит, 1 нче кисәк). | 1 | | |
| | | Тәрҗемә әсәрләр (1 сәг.) | | | |
| 31. | 1. | Андрей Платонов. “Ягъфәр бабай” хикәясен укып анализлау (117-119 нчы бит, 1 нче кисәк). | 1 | | |
| | | Язучылар иҗатында юмор (2+1 сәг.) | | | |
| 32. | 1. | Алмаз Гыймадиев. “Телефонлы кәҗә”. “Интернетта – ALF!” хикәяләрен укып анализлау (120-124 нче бит, 1 нче кисәк). | 1 | | |
| 33. | 2. | Ләбиб Лерон. “Зөһрә кыз – безнең авылдан” хикәясен укып анализлау (125-126 нчы бит, 1 нче кисәк). | 1 | | |
| 34. | 3. | Ел буе үткәннәрне кабатлау. Контроль эш. | 1 | | |

**мәҗбүри укылырга тиешле әсәр.*